ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ ЛЕНИН УРАМЫ ЙОРТ 76 "а"

тел.+7(84396) 2-64 -66 тел./факс +7(84396) 2-64-66

423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ УЛИЦА ЛЕНИНА ДОМ 76 «а»

№131 05.03.2025 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Бәркәтә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советының
2012 елның 27 декабрендәге
«Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлегенең җирдән
файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында»
№ 26 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 26 декабрендәге № 485-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27 декабрендәге 26 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 2,3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлының юл буе полосалары - беренче, икенче яисә өченче категорияле автомобиль юлына бүленгән полосага ике яктан да якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау, карап тотуның, автомобиль юлының үсеш перспективаларын исәпкә алып, аның сакланышының нормаль шартларын тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир

кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр.

Зона параметрлары һәм зонадагы эшчәнлекне чикләү «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сибгатуллин